**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «09» гыйнварыннан № 1

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында

Аерым категориядәге гражданнар өчен социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының 2 абзацы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Кушымтада бирелгән Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетын махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирүне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләүне билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) турында нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.

4. Комиссия составын расларга (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына 2025 елга бюджет язмасында каралган акчалар чикләрендә махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү белән бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карар 2025 елның 9 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
беренче урынбасары (икътисад буенча) Л.К. Исхакова

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «09» гыйнварыннан
1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибе

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү рәвешендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан аерым гражданнарга социаль ярдәмнең өстәмә чарасы (алга таба – бер тапкыр түләү) күләмен, аны билгеләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын билгели.

1. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләме

1.1. Бер тапкыр түләү күләме – 200 000,00 (Ике йөз мең) сум.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирү шартлары

2.1. Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү контракт буенча (алга таба - Контракт) хәрби хезмәткә сайлап алу пунктында башкарыла.

2.2. Бер тапкыр түләү 2025 елның 09 гыйнварыннан 2025 елның 26 декабренә кадәрге чорда Контракт төзегән гражданнарга бирелә.

3. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе

3.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү алу өчен Контракт төзегән Россия Федерациясе гражданы (алга таба - контрактчы) контракт буенча хәрби хезмәткә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы вәкаләтле органына - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә тутырылган бер тапкыр бирелә торган түләү бирү турында гариза (алга таба - Гариза) җибәрә.

3.2. Әлеге Тәртипне үтәүне оештыруга җаваплы булып Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының икътисадый анализ, бухгалтерлык исәбе һәм контракт эшчәнлеге бүлеге (алга таба - Бүлек) тора.

3.3. Документлар теркәлгән гариза Контракт төзелгән көннән алып 2025 елның 27 декабренә кадәр вәкаләтле органга түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә ав., Совет урамы 80, 201 нче кабинет. Контакт телефоны: 8 (843-48) 2-21-65.

3.4. Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

контрактчының фамилиясе, исеме, атасының исеме;

контрактчының шәхесен таныклый торган документ турында мәгълүматлар (төр, бирү вакыты, реквизитлары);

ИНН;

СНИЛС

- контрактчының туу датасы (көне, ае, елы);

теркәлү урыны адресы һәм контрактчының яшәү урыны адресы (булган очракта);

кредит оешмасында контрактчы ачкан счетның реквизитлары;

- Контракт төзелгән урын буенча хәрби комиссариат турында мәгълүмат;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

3.5. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан хәрби комиссариатның махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында граждан тарафыннан контракт төзүне раслаучы әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә тутырылган белешмәсе.

аны теркәүне раслаучы битне дә кертеп, контрактчының паспорты күчермәсе, тору урыны буенча теркәү турында таныклык (булган очракта);

- ИНН (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) күчермәсе;

СНИЛС (мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры) күчермәсе ;

бер тапкыр түләнә торган түләүне күчерү өчен банк реквизитлары белән контрактчының счеты күрсәтелгән басма.

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

3.6. Бер тапкыр бирелә торган түләү алу өчен мөрәҗәгать иткәндә контрактчы шәхесен раслаучы документ күрсәтә.

3.7. Бер тапкыр бирелә торган түләү алу өчен документлар җыелмасы белән гаризаны контрактчы исеменнән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат бирергә хокуклы.

3.8. Гариза вәкаләтле вәкил тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүче шәхесен раслаучы документ һәм ышанычнамә күрсәтә. Әлеге документларның күчермәләре һәм (яисә) төп нөсхәләре гаризага теркәлә.

3.9. Бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәге очракларда кире кагыла:

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә, шулай ук белә торып дөрес булмаган, ялган белешмәләр (документлар) тапшырылганда;

әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә бер тапкыр бирелә торган түләүгә хокукы булмаганда (шул исәптән хәрби комиссариат мәгълүматлары буенча);

бер тапкыр бирелә торган түләүне алу өчен әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән документлар бирү вакыты чыкканда (туры килмәгәндә).

3.10. Бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү йә бирүдән баш тарту турындагы карар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына белешмәләр кергәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3.11. Карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә Бүлек контрактчыга Гаризада күрсәтелгән ысул белән бер мәртәбә түләү билгеләү яисә кире кагу турында хәбәр итә.

3.12. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына Комиссия карарының таныкланган күчермәсен һәм керем алучының карточкасын рәсмиләштерү һәм бер тапкыр түләнә торган түләүне күчерү өчен контрактчыларның персональ белешмәләре булган документларның таныкланган күчермәләрен тапшыра.

3.13. Бер тапкыр бирелә торган түләү Комиссия карары нигезендә 5 эш көне эчендә башкарыла.

3.14. Бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү буенча барлык документларның төп нөсхәләре Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының икътисадый анализ, бухгалтерлык исәбе һәм контракт эшчәнлеге бүлегендә законнарда билгеләнгән срокларда саклана.

3.15. 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон нигезендә контрактчының шәхси мәгълүматларын саклау һәм конфиденциальлек тәэмин ителә.

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан
Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби
хезмәт узу турында контракт төзегән Россия
Федерациясе гражданнарына бер тапкыр
акчалата түләү бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетына
______ елның ________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
теркәлү адресы ___________________________
____________________________________
паспорт: сериясе ________ номеры __________
_______________________________ бирелгән
*(паспортны бирү датасы, кем тарафыннан бирелүе)*
____________________________________
____________________________________
____________________________________
Тел. ____________ ________________

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 09 гыйнварындагы 1 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән ____________________________________,
*(контрактчының фамилиясе, исеме, атасының исеме)*
Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүгә

Гариза

РФ гражданины паспорты серия ____ №_______ бирелү вакыты «_»_____ ____ел ___________________________________________ тарафыннан бирелгән, бүлекчә коды _______
*(туу датасы) (паспорт: серия, номер, кем тарафыннан, кайчан бирелгән)*
Теркәлү урыны: ________________________________________,
Яшәү урыны: __________________________________________,
махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында килешү төзүчегә.
Контракт төзелгән _____________________________________
*(контрактны төзү датасы)*

Хәрби комиссариат исеме: ________________________________________________________________________

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүне сорыйм:
банкның идентификация коды __________ ____________________________________________________,
(кредит оешмасының тулы исеме)
/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/__/_/_/ номерлы шәхси счетка _______________________________________________________________
исеменә
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
Кушымта:
1. контрактчының паспорты күчермәсе
2. гариза бирүченең (контрактчының) банк реквизитлары
3. хәрби комиссариаттан белешмә
4. Салым түләүченең ИИН (тәңгәлләштерү номеры) күчермәсе, СНИЛС (мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры) күчермәсе;
5. шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында документ
Өстәмә рәвештә теркәлә (әгәр гариза контрактчының ышанычнамәсе нигезендә вәкаләт бирелгән зат тарафыннан тапшырылса):
шәхесне таныклаучы документ: ____________________________ ________________________________________________________________,
- ышанычнамә.
Кабул ителгән карар турында хәбәр итү ысулы:
1. Почта __________________________________________________
*(адресны күрсәтергә)*
2. Электрон адрес __________________ телефон аша хәбәр ________________
*(электрон почта адресын күрсәтергә)*
Гаризада булган мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.
Күрсәтелгән түләүләр бер вакытта бер тапкыр башкарылуы турында таныштым.
Бер тапкыр бирелә торган түләүне башкару максатыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм тапшыруга ризалыгымны бирәм.
20___ елның «____» ___________ _______________/________________________/
(гариза бирүче имзасы, имзаның аңлатмасы)
20___ елның «____» ___________ _______________/________________________/

(гариза кабул иткән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының икътисадый анализ, бухгалтерлык исәбе һәм контракт эшчәнлеге бүлеге башлыгы имзасы һәм имзасының аңлатмасы)

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан
Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби
хезмәт узу турында контракт төзегән Россия
Федерациясе гражданнарына бер тапкыр
акчалата түләү бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Почмаклы штамп
Белешмә бирү датасы:_____________

Белешмә

түбәндәгеләр турында бирелгән: ________________________________________
*(контрактчының фамилиясе, исеме, атасының исеме)*
шәхесне раслаучы документы (паспорт): сериясе_______, номеры______________, кем тарафыннан, кайчан бирелгән _________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
202_____ елның __________________ махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән _________________________________________ вакытка исәпләнгән Контракт төзеде һәм чынлыкта ___________________ хәрби часть карамагына китте,
махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби часть исемлекләренә кертелде (датасы ______________________ номеры_________)
Белешмә бирү нигезе _______________________________________.
Вазифа атамасы: ___________________________________________________.
имза ________________ ______________________
имзаның аңлатмасы

Мөһер урыны

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан
Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби
хезмәт узу турында контракт төзегән Россия
Федерациясе гражданнарына бер тапкыр
акчалата түләү бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ________________________________________________________________,
________________________________________ (ФИА.и.), _____________ туган елы,
паспорт сериясе ______________ № ______________, __________________
тарафыннан ______________________________________________________бирелгән
адрес: __________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында» 2025 елның 09 июлендәге 1 номерлы карары нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә акчалата түләү бирү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм. Әлеге ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар гаризада һәм тәкъдим ителгән документларда күрсәтелгән белешмәләрне, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме;

шәхесне таныклый торган документ турында мәгълүматлар (төр, бирү вакыты, реквизитлары);

ИНН;

СНИЛС

туган көне;

теркәлү урыны һәм яшәү урыны (тору урыны) адресы, кредит оешмасында ачылган акча түләүләрен күчерү өчен хисап счетлары турындагы белешмәләр.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү буенча эшләр түбәндәгеләрне үз эченә ала: җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), алу, файдалану, тапшыру (тарату, тәкъдим итү, файдалану өчен мөмкинлек бирү), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, чикләү, юкка чыгару, шәхси мәгълүматларны бетерү.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү автоматлаштыру чараларын кулланмыйча гамәлгә ашырыла.

Ризалык бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүгә гариза биргәннән алып минем тарафтан әлеге ризалыкны язма рәвештә кайтарганга кадәр гамәлдә була.

__________________________________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалыкны бирү датасы:
20__ елның «____»________________

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «09» гыйнварыннан
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү комиссиясе турында нигезләмә

1. Муниципаль акчалар бүлеп бирү турында карарлар кабул итү комиссиясе Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында махсус хәрби операциядә катнашу максатларында 2025 елның 09 гыйнварыннан 2025 елның 30 декабренә кадәр чорда контракт (алга таба - Контракт) төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаризаларын карый.

2. Комиссия утырышлары Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә махсус хәрби операциядә катнашу максатларында хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә акчалата түләү бирү Тәртибендә каралган гаризалар кергән һәм документлар тупланган саен уздырыла.

3. Акчалата түләү бирү турында карар, шулай ук акчалата түләү бирүне кире кагу турында карар Комиссия тарафыннан Комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән гариза теркәлгән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Беркетмә Комиссиянең рәисе һәм визаланган секретаре тарафыннан раслана.

4. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы булып тора. Карар, ачык тавыш биреп, күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

5. Комиссия эшчәнлеге белән Комиссия рәисе идарә итә, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары.

Бер тапкыр акчалата түләү бирү турындагы беркетмә проекты Комиссия карары кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Комиссия сәркатибе тарафыннан рәсмиләштерелә.

Карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты контрактчыга Гаризада күрсәтелгән ысул белән бер мәртәбә түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «09» гыйнварыннан
1 номерлы карарына
3 нче кушымта

Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Фасахов Ринат Рифгать улы | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Исхакова Луиза Камил кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча); |

Комиссия сәркатибе:

| | | |
|---|---|---|
| Зевакина Ольга Вениаминовна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе (мобилизация эше буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Гурьева Наталья Николаевна | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Еронтьев Александр Леонидович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) |
| Завалишина Наталья Александровна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| Завалишина Ольга Владимировна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының икътисадый анализ, бухгалтер исәбе һәм контракт эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |